Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«13» ноябрь 2022 ел № 10

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Әмзә авыл җирлегенең Яңа Әмзә авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Чүплекне рекультивацияләү;

- Яңа Әмзә торак пунктында авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту.

Халык җыенында рәислек итүче: Ә.Ф.Сафиуллина

Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина